# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ

# ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

## № 6

ИЮНЬ

1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
КАЗАН
1999

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҖЫЕЛМА БАСМАСЫ

*№ 6*
*июнь*
*1999*

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
РӘСМИ БАСМАСЫ
Казан
1997

Лицензия № 174 1996 елның 03.10 бирелде
Җитештерүгә тапшырылды
Формат А5. Оригинал-макеттан басылды
Тиражы 1150 нөсхә. Заказы №002367
Бәясе килешү буенча.
"АБАК" нәшрияты.
420045 Казан, Н.Ершов ур., 31б.
Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять АБАК-хезмәт күрсәтү үзәгендә басылды
Лицензия № 0080 1997 елның 03.12 бирелде
420107 Казан, Һади Такташ ур., 105

*ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ 78696*
**Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы:**
© Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәсми басмасы

## Эчтәлек

## I

562.“Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеге хакында” *Татарстан Республикасы Законы* ..... 6

563.“Алабуга” ирекле икътисадый зонасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” *Татарстан Республикасы Законы* ..... 7

564.Татарстан Республикасы Конституциясенең 111 статьясына үзгәреш һәм өстәмә кертү турында” *Татарстан Республикасы Законы* .. 9

565.“Иминлек турында” *Татарстан Республикасы Законы* ..... 10

566.“Иминлек турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..... 17

567.“Татарстан Республикасының бюджеттан тыш дәүләт фондлары турында” *Татарстан Республикасы Законы* ..... 18

568.“Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында ” *Татарстан Республикасы Законы* ..... 21

569.“1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” *Татарстан Республикасы Законы* ..... 22

570.“1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотик чараларны явыз ниятләрдә куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы гамәлләрнең республика комплекслы программасы турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..... 25

571.“Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 16 июньдәге утырышы көн тәртибе турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..... 26

572.“Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм Татарстан Республикасы Чирмешән район суды рәисен, Татарстан Республикасының □лмәт, Түбән Кама шәһәр судлары рәисләренең урынбасарларын раслау турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..... 28

573.“Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының 9 гыйнвар исемендәге поселогын Тенеш поселогы дип үзгәртеп исемләү турында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..... 29

574.“Татарстан Республикасы мировой судьяларының гомуми саны һәм суд участоклары саны турында” федераль закон проектын Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында” *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ..... 29

575."Жирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 30

576."Наркотик чараларга һәм психотроп матдәләргә бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 31

577."16 яше тулмаган балигъ булмаганнарның терроризм акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 32

578."Татарстан Республикасында көн күрерлек минимум турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күрә торган чаралар хакында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 33

579."Хезмәт ветераны" исеме бирүгә гаризаларны һәм документларны кабул итү, аларны исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм аны тапшыру тәртибе турындагы инструкцияне раслау хакында" Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге 1030 нчы карарының Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм гамәлдәге законнарга туры килүе турында" Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитетының 1999 елның 16 февралендәге бәяләмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күргән чаралар хакында мәгълүмат турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 34

580.Татарстан Республикасы Дәүләт Советының язгы сессиясен озайту турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары* ........ 35

## II

581.Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 36

582.Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 16 июньдәге утырышы көн тәртибенә кертелүче мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 36

583.1999 елның 26 июнендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........ 38

584.Татарстан Республикасы халык депутатларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы

утырышында әйтелгән тәкъдимнәре турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ............................ 39
585."Татарстан Республикасы халык депутатларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 26-27 маендагы XIX пленар сессиясендә әйтелгән тәкъдимнәре турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ...................... 39
586."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен дәвам итү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ....................................................... 40
587."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .... 41
588."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* .... 42
589."Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен дәвам итү көнен үзгәртү турында" *Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары* ........................... 43

# I
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАБУЛ ИТКӘН ЗАКОННАР ҺӘМ КАРАРЛАР

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 562. Продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеге хакында

1 статья. "Нефть һәм газ турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә продукцияне бүлешү турындагы килешүләр шартларында файдалану хокукы бирелергә мөмкин булган җир асты байлыклары кишәрлекләренең түбәндәге исемлеген расларга:

1. Алексеевский нефть ятмасы
2. Байданкино нефть ятмасы
3. Югары Уратма нефть ятмасы
4. Көнчыгыш Макаровка нефть ятмасы
5. Глазово нефть ятмасы
6. Дачный нефть ятмасы
7. Елга арьягы нефть ятмасы
8. Кама арьягы нефть ятмасы
9. Лангуево нефть ятмасы
10. Җәйге нефть ятмасы
11. Кызыл Октябрь нефть ятмасы
12. Макаровка нефть ятмасы
13. Мөслим нефть ятмасы
14. Мөхәрмәтов нефть ятмасы
15. Нагорный нефть ятмасы
16. Түбән Уратма нефть ятмасы
17. Яңа Чишмә нефть ятмасы
18. Нөркәй нефть ятмасы
19. Төньяк нефть ятмасы
20. Сотниково нефть ятмасы
21. Якты Күл нефть ятмасы
22. Иске Кади нефть ятмасы

23. Тау Иле нефть ятмасы
24. Ульяновка нефть ятмасы
25. Уратма нефть ятмасы
26. Урганча нефть ятмасы
27. Чәкән нефть ятмасы

2 статья. Әлеге Закон матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае

№ 2147

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 563. "Алабуга" ирекле икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1 статья. "Алабуга" ирекле икътисадый зонасы турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, №5) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяда:

түбәндәге редакциядә өченче абзац өстәргә:

"Алабуга" ирекле икътисадый зонасы инфраструктурасы — ирекле икътисадый зона территориясендә җитештерү һәм хуҗалык эшчәнлеге өчен шартлар тәэмин итүгә билгеләнгән элементлар җыелмасы, аңа түбәндәгеләр керә: киртәләр, биналар һәм корылмалар, территориянең инженерлык корылышы, әйләнә-тирә мохитне саклау объектлары, шулай ук Ирекле икътисадый зонада хезмәткәрләрне социаль тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итә торган объектлар";

өченче, дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче абзацларны дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче, тугызынчы абзацлар дип санарга.

статьяга түбәндәге редакциядә унынчы абзац өстәргә:

"Товар — Ирекле икътисадый зонада катнашучылар тарафыннан Ирекле икътисадый зона территориясендә җитеш-

терелгән һәм аннан читкә сатып җибәрү өчен билгеләнгән продукция".

2. 7 статьяда: түбәндәге редакциядә беренче өлеш өстәргә:

"Ирекле икътисадый зона инфраструктурасыннан файдаланган өчен түләү алу Ирекле икътисадый зонада катнашучыга инфраструктура элементларыннан файдалану мөмкинлеге бирелгән өчен башкарыла";

беренче өлешне икенче өлеш дип санарга;

беренче өлешнең икенче абзацын икенче өлешнең икенче абзацы дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- Ирекле икътисадый зонаның инфраструктурасыннан файдаланган өчен - читкә чыгарыла торган товарлар бәясеннән (өстәлгән бәяләргә салымны исәпкә алмыйча) ике процентка кадәр, ул күләмне Ирекле икътисадый зона администрациясе билгели";

беренче өлешнең өченче абзацын икенче өлешнең өченче абзацы дип санарга;

икенче өлешне өченче өлеш дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җир кишәрлекләрен арендалаган һәм хезмәт күрсәткән өчен түләүләрнең вакытлары, тәртибе һәм күләмнәре, Ирекле икътисадый зонаның эшчәнлеге үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә";

өченче өлешне дүртенче өлеш дип санарга;

статьяга түбәндәге редакциядә бишенче өлеш өстәргә:

"Хезмәт күрсәткән өчен һәм Ирекле икътисадый зона операторы белән төзелгән шартнамә буенча территорияне инженерлык корылышы объектларына тоташтырган өчен Ирекле икътисадый зонада катнашучыларның түләүләре Ирекле икътисадый зона инфраструктурасыннан файдаланган өчен түләүләргә кертелми";

дүртенче һәм бишенче өлешләрне алтынчы һәм җиденче өлешләр дип санарга.

3. 10 статьяның өченче өлешендәге алтынчы абзацында "җир кишәрлекләрен," дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

4. 14 статьяда: түбәндәге редакциядә икенче өлеш өстәргә:

"Ирекле икътисадый зона администрациясенә Ирекле икътисадый зона территориясендә урнашкан җир кишәрлек-

ләрен арендага тапшыру буенча вәкаләтләр бирелә";

иkенче өлешне өченче өлеш дип санарга.

5. 17 статьяның бишенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ирекле икътисадый зона территориясендә тиешле квалификация эшләрен башкару өчен чит ил гражданнарын, шул исәптән чит ил эшчеләрен җәлеп итү Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла".

2 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты 2 ай эчендә үзенең норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 20 мае
№ 2149

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 564. Татарстан Республикасы Конституциясенең 111 статьясына үзгәреш һәм өстәмә кертү турында

Әлеге Закон шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең, Татарстан Республикасы суверенитетының иминлеген комплекслы тәэмин итү максатларында кабул ителә.

1 статья. Татарстан Республикасы Конституциясенең 111 статьясына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 9-10; 1994, № 11; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1995, № 2-3, № 12; 1996, № 11) түбәндәге үзгәрешне һәм өстәмәне кертергә:

1. 111 статьяга түбәндәге эчтәлекле 18 нче яңа пункт өстәргә:

"18) Татарстан Республикасының Иминлек Советын төзи һәм аңа җитәкчелек итә, аның статусы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә".

2. 111 статьяның 18 пунктын 19 пункт дип санарга.

2 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 26 мае
№ 2180

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 565. Иминлек турында

Әлеге Закон шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең, Татарстан Республикасының һәм, аның аерылгысыз сыйфат халәте буларак, суверенлыгының иминлеген тәэмин итүнең хокукый нигезләрен беркетә, Татарстан Республикасында иминлек системасын һәм аның эшчәнлеген билгели, Татарстан Республикасының иминлеген тәэмин итү органнарының оешу тәртибен һәм аларны финанслау тәртибен билгели.

**I бүлек. Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Иминлек төшенчәсе һәм аның объектлары**

Иминлек – шәхеснең, җәмгыятьнеңа һәм Татарстан Республикасы дәүләтенең тормыш өчен әһәмиятле мәнфәгатьләренең эчке һәм тышкы янаулардан якланганлык халәте.

Тормыш өчен әһәмиятле мәнфәгатьләр – аларны канәгатьләндерү шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең яшәешен һәм прогрессив үсеш мөмкинлеген тәэмин итә торган ихтыяҗлар берлеге.

Иминлеккә янау – шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең тормыш өчен әһәмиятле мәнфәгатьләренә куркыныч тудыручы шартлар һәм факторлар берлеге.

Иминлекнең төп объектларына түбәндәгеләр керә: шәхес – аның хокуклары һәм ирекләре; җәмгыять – аның матди һәм рухи хәзинәләре; Татарстан Республикасы – аның конституциячел корылышы, суверенлыгы һәм территориаль бөтенлеге, социаль-сәяси һәм икътисадый тотрыклылыгы.

2 статья. **Иминлекне тәэмин итү субъектлары**

Иминлекне тәэмин итүнең төп субъекты закон чыгару, башкарма һәм суд хакимиятләре органнары аша бу өлкәдә эшчәнлек башкаручы дәүләттән гыйбарәт.

Татарстан Республикасы үз Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә һәр кешенең иминлеген гарантияли. Татарстан Республикасыннан читтәге Татарстан Республикасы гражданнарына Татарстан Республикасының хокукый яклавы һәм ярдәме гарантияләнә.

Җәмәгать һәм башка төрле оешмалар һәм берләшмәләр, гражданнар иминлек субъектлары булалар, законнар нигезендә иминлекне тәэмин итүдә катнашуга хокуклылар һәм бурычлылар. Татарстан Республикасы иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүче гражданнарга, җәмәгать һәм башка оешмаларга һәм берләшмәләргә закон нигезендә хокукый һәм социаль яклау гарантияли.

3 статья. **Татарстан Республикасында иминлекне тәэмин итүнең закон чыгару нигезе**

Татарстан Республикасында иминлекне тәэмин итүнең кануный нигезе Татарстан Республикасы Конституциясеннән, әлеге Законнан, иминлек өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы законнардан һәм башка закон актларыннан, Татарстан Республикасы төзегән шартнамәләрдән һәм килешүләрдән гыйбарәт.

4 статья. **Иминлекне тәэмин итү принциплары**

Иминлекне тәэмин итүнең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

законлылыктан;

шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең тормыш өчен әһәмиятле мәнфәгатьләренең нисбәтен саклаудан;

иминлекне тәэмин итүдә шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең үзара җаваплылыгыннан;

иминлек буенча республикара системалар белән интеграцияләнүдән;

барлыкка килүче янауларны көч кулланмый торган ысуллар белән кисәтүдән;

иминлекне тәэмин итү системасы органнары эшчәнлеген тиешле законнар белән катгый регламентацияләүдән.

5 статья. **Иминлекне тәэмин итү**

Иминлеккә Татарстан Республикасында шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең тормыш өчен әһәмиятле мәнфәгатьләренә янауларга каршы торырлык икътисадый, сәяси, оештыру һәм башка характердагы гамәлләр системасы, иминлекне тәэмин итү өлкәсендәге бердәм дәүләт сәясәте үткәрү белән ирешелә.

Татарстан Республикасында иминлек объектларын яклауның кирәкле дәрәҗәсен барлыкка китерү һәм тоту өчен иминлек өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы хокукый нормалар системасы эшләнә, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының бу өлкәдәге эшчәнлегенең төп юнәлешләре билгеләнә, иминлекне тәэмин итү органнары һәм аларның эшчәнлеген тикшереп тору һәм күзәтү механизмы булдырыла яисә үзгәртеп корыла.

Татарстан Республикасында шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү функцияләрен турыдан-туры үтәү өчен закон нигезендә иминлекне тәэмин итүнең дәүләт органнары төзелә.

6 статья. **Иминлекне тәэмин иткәндә гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау**

Иминлекне тәэмин иткәндә, законда турыдан-туры каралган очраклардан гайре, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә юл куелмый.

Гражданнар, җәмәгать һәм башка төрле оешмалар һәм берләшмәләр иминлекне тәэмин итүче органнардан үзләренең хокукларын һәм ирекләрен чикләү буенча аңлатмалар алырга хокуклы. Мондый аңлатмалар алар таләбе буенча законнарда билгеләнгән вакытта язма рәвештә биреләләр.

Иминлекне тәэмин итү эшчәнлеге барышында үз вәкаләтләрен арттырган, шулай ук үзләренең хезмәт вазыйфаларын үтәмәүгә яисә тиешенчә үтәмәүгә юл куйган урындагы затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

## II бүлек. Татарстан Республикасының иминлек системасы

7 статья. **Татарстан Республикасы иминлек системасының төп элементлары**

Татарстан Республикасының иминлек системасын закон чыгару, башкарма, суд хакимиятләре органнары, дәүләт, җәмәгать һәм башка оешмалар һәм берләшмәләр, иминлекне тәэмин итүдә закон нигезендә катнашучы гражданнар, шулай ук иминлек өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы законнар тәшкил итә.

Татарстан Республикасы законы белән билгеләнмәгән иминлекне тәэмин итү органнарын Татарстан Респуб-

ликасында төзү рөхсәт ителми.

8 статья. **Иминлек системасының төп функцияләре**

Татарстан Республикасы иминлек системасының төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

иминлек объектларының тормыш өчен әһәмиятле мәнфәгатьләренә карата эчке һәм тышкы янауларны фаразлаудан һәм ачудан, аларны булдырмый калу һәм нейтральләштерү буенча оператив һәм озакка сузылган гамәлләр комплексын башкарудан;

иминлекне тәэмин итү көчләрен һәм чараларын булдырудан һәм аларны әзерлек хәлендә тотудан;

иминлекне тәэмин итү көчләренә һәм чараларына көндәлек шартларда һәм гадәттән тыш хәлләрдә идарә итүдән;

республиканың гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу нәтиҗәсендә зыян күргән районнарында һәм шәһәрләрендә иминлек объектларының нормаль эшләвен торгызу чаралары системасын башкарудан;

Татарстан Республикасы төзегән шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы чикләреннән читтә иминлекне тәэмин итү гамәлләрендә катнашудан.

9 статья. **Иминлек тәэмин итү көчләре һәм чаралары**

Татарстан Республикасында иминлек тәэмин итү көчләре һәм чаралары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, иминлекне тәэмин итү буенча кыска вакытлы һәм озакка сузылган республика программалары һәм федераль программалар, шулай ук Татарстан Республикасы төзегән шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә төзелә һәм үстерелә.

Татарстан Республикасы территориясендә иминлек көчләренә түбәндәгеләр керә: дәүләт иминлегенең, эчке эшләрнең, салым хезмәтенең республика органнары; дәүләт хакимияте органнарының һәм иң югары урындагы затларның иминлеген тәэмин итү хезмәтләре; гадәттән тыш хәлләрнең тискәре нәтиҗәләрен бетерү хезмәтләре, гражданнар оборонасы төзелмәләре, сәнәгатьтә, энергетикада, транспортта һәм авыл хуҗалыгында эшләрне имин алып баруны тәэмин итүче органнар; элемтә һәм мәгълүмат чараларының, таможняның иминлеген тәэмин итү хезмәтләре, табигатьне саклау органнары, халыкның сәламәтлеген саклау органнары һәм иминлекне тәэмин итүнең законнар нигезендә эш итүче башка дәүләт органнары.

Татарстан Республикасы Дәүләт иминлеге комитетының, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең үз эшчәнлекләрендә махсус көчләр һәм чаралар кулланучы башка органнары бары тик Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә генә эш итәләр.

Иминлекне тәэмин итү органнарының җитәкчеләре үз эшчәнлекләренең билгеләнгән тәртибен бозган өчен законнар нигезендә җаваплы булалар.

Иминлекне тәэмин итү көчләре үз эшчәнлекләрен Россия Федерациясенең иминлекне тәэмин итү буенча тиешле көчләре белән килештереп гамәлгә ашыралар.

## III бүлек. Татарстан Республикасының Иминлек Советы

### 10 статья. Татарстан Республикасы Иминлек Советының статусы

Татарстан Республикасының Иминлек Советы Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының иминлекне тәэмин итү өлкәсендәге карарларын әзерләүне гамәлгә ашыручы конституциячел орган була. Татарстан Республикасының Иминлек Советы иминлек тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының эчке һәм тышкы сәясәт мәсьәләләрен, иминлекнең дәүләти, икътисадый, иҗтимагый, оборона, мәгълүмати, экологик һәм башка төр стратегик проблемаларын, халыкның сәламәтлеген саклау, гадәттән тыш хәлләрне фаразлау, аларны булдырмый калу һәм аларның тискәре нәтиҗәләрен бетерү, тотрыклылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итү проблемаларын карый, алар буенча тиешле тәкъдимнәр һәм күрсәтмәләр әзерли.

Татарстан Республикасының Иминлек Советы үз эшчәнлеген әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы Президенты раслаган Татарстан Республикасының Иминлек Советы турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

### 11 статья. Татарстан Республикасы Иминлек Советының составы һәм аны төзү тәртибе

Татарстан Республикасының Иминлек Советы составына Иминлек Советы рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм әгъзалары керә.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфалары буенча Иминлек Советы Рәисе була.

Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе вазыйфалары буенча Татарстан Республикасының Иминлек Советы Рәисе урынбасарлары булалар.

Иминлек Советының персональ составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

Каралучы мәсьәләнең асылыннан чыгып, Татарстан Республикасының Иминлек Советы Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының урындагы затларын, экспертларны, белгечләрне һәм консультантларны утырышта катнашырга җәлеп итә ала.

### 12 статья. **Татарстан Республикасы Иминлек Советының төп бурычлары**

Татарстан Республикасы Иминлек Советының төп бурычларына түбәндәгеләр керә: иминлек объектларына эчке һәм тышкы янауларны билгеләү һәм фаразлау; Татарстан Республикасы иминлеген тәэмин итү стратегиясенең төп юнәлешләрен эшләү һәм аны тәэмин итүнең республика программаларын әзерләүне оештыру;

шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эчке һәм тышкы сәясәт мәсьәләләре буенча карарлар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына тәкъдимнәр әзерләү;

гадәттән тыш хәлләрне булдырмый калу буенча һәм аларны бетерүне оештыру буенча оператив тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасында һәм аның аерым урыннарында гадәттән тыш хәл кертү, аны озайту яисә юкка чыгару турында Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү;

иминлек өлкәсендә кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру барышында Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарының эшчәнлеген җайга салу буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген билгеләү;

шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итүче гамәлдәге органнарны үзгәртеп кору йә яңаларын төзү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

### 13 статья. **Татарстан Республикасының Иминлек Советы тарафыннан карарлар кабул итү тәртибе**

Татарстан Республикасының Иминлек Советы утырыш-

лары кимендә ике айга бер мәртәбә уздырыла. Кирәк булган очракта Советның чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасының Иминлек Советы әгъзалары карарлар кабул иткәндә бертигез хокукларга ия булалар.

Татарстан Республикасының Иминлек Советы карарлары Иминлек Советы әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавышы белән кабул ителәләр һәм Татарстан Республикасының Иминлек Советы Рәисе раслаганнан соң үз көченә керәләр.

Татарстан Республикасы Иминлек Советының иминлекне тәэмин итү мәсьәләләре буенча карарлары Татарстан Республикасы Президенты указлары белән рәсмиләштереләләр.

14 статья. **Татарстан Республикасы Иминлек Советының ведомствоара комиссияләре**

Татарстан Республикасының Иминлек Советы үз эшчәнлегенең төп бурычлары нигезендә ведомствоара даими комиссияләр төзи. Гадәттән тыш хәлләрне булдырмый калу һәм алардан килгән зыянны бетерү, җәмгыятьтә һәм дәүләттә тотрыклылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итүнең аерым проблемалары, Татарстан Республикасының конституциячел корылышын, аның суверенитетын һәм территория бөтенлеген яклау буенча тәкъдимнәр әзерләргә кирәк булган очракта Татарстан Республикасының Иминлек Советы тарафыннан ведомствоара вакытлыча комиссияләр төзелергә мөмкин.

Эшчәнлекнең төп юнәлешләре, вәкаләтләре, даими һәм вакытлыча ведомствоара комиссияләрне оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасының Иминлек Советы турында нигезләмә белән регламентлана.

Татарстан Республикасының Иминлек Советы карары буенча даими һәм вакытлыча ведомствоара комиссияләргә Иминлек Советы әгъзалары, шулай ук Татарстан Республикасының тиешле министрлыклары, дәүләт комитетлары һәм ведомстволары җитәкчеләре йә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан шуңа вәкаләтләр бирелгән башка затлар җитәкчелек итә ала.

15 статья. **Татарстан Республикасының Иминлек Советы эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати тәэмин итү**

Татарстан Республикасының Иминлек Советы эшчән-

леген оештыру-техник һәм мәгълүмати тәэмин итүне Татарстан Республикасы Президенты Аппараты гамәлгә ашыра.

## IV бүлек. Татарстан Республикасында иминлекне тәэмин итү эшчәнлеген финанслау

**16 статья. Татарстан Республикасында иминлекне тәэмин итү эшчәнлеген финанслау**

Татарстан Республикасында иминлекне тәэмин итү эшчәнлеген финанслау, программаларның асылыннан һәм масштабларыннан, гадәттән тыш вәзгыятьләрнең һәм аларның нәтиҗәләреннән чыгып, федераль бюджет (иминлек тәэмин итүнең федераль программаларын гамәлгә ашыру өлешендә), Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән, шулай ук бюджеттан тыш чаралар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## V бүлек. Иминлекне тәэмин итү эшчәнлеген тикшереп тору

**17 статья. Иминлекне тәэмин итү эшчәнлеген тикшереп тору**

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары министрлыкларның, дәүләт комитетларының һәм ведомстволарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның иминлекне тәэмин итү эшчәнлекләрен үз вәкаләтләре чикләрендә тикшереп торалар.

Татарстан Республикасының иҗтимагый һәм башка берләшмәләре, оешмалары, гражданнары иминлекне тәэмин итүче органнарның эшчәнлеге турында законнар нигезендә мәгълүмат алырга хокуклы.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 26 мае
№ 2181

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 566. “Иминлек турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

“Иминлек турында” Татарстан Республикасы Законын матбугатта басылган көннән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәмммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 26 мае
№ 2182

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 567. Татарстан Республикасының бюджеттан тыш дәүләт фондлары турында

Әлеге Закон бюджеттан тыш республика фондларын (Татарстан Республикасының бюджеттан тыш дәүләт фондларын) оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең хокукый нигезләрен билгели.

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары - Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль үсеш дәүләт максатчан программаларын финанс ягыннан тәэмин итүче дәүләт учреждениеләре.

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары турындагы законнар әлеге Законнан һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары эшчәнлеген җайга салучы башка закон актларыннан гыйбарәт.

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары үз эшчәнлекләрен әлеге Закон һәм, әлеге Закон нигезендә әзерләнгән һәм расланган нигезләмәләргә (уставларга) таянып, законнар нигезендә алып бара.

Бюджеттан тыш дәүләт фондларының исемнәре аларның гамәлгә кую документларында билгеләнә.

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары юридик зат булып торалар, законнар нигезендә филиаллар төзергә һәм вәкилләкләр ачарга мөмкиннәр.

2 статья. **Бюджеттан тыш дәүләт фондларының төп бурычлары һәм вазыйфалары**

Бюджеттан тыш дәүләт фондларының төп бурычлары һәм вазыйфалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

законнар нигезендә бюджеттан тыш дәүләт фондларына керүче финанс чараларын җыюдан, туплаудан, исәпкә алудан һәм максатчан файдаланудан;

дәүләтнең максатчан икътисадый һәм социаль үсеш программаларын финанслауны тәэмин итүдән, аларны әзерләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашудан;

бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчалары исәбеннән финансланучы максатчан дәүләт программалары һәм шартнамәләре проектларын экспертизалауны оештырудан һәм аларда катнашудан;

бюджеттан тыш дәүләт фондлары алдына куелган бурычларны хәл итүгә законнар нигезендә өстәмә акчалар җәлеп итүдән;

бюджеттан тыш дәүләт фондлары эшчәнлеге мәсьәләләре буенча тышкы икътисадый багланышларны үстерүдән;

бюджеттан тыш дәүләт фондларына түләүләр, җыемнар һәм акча күчерүләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшереп торудан.

3 статья. **Бюджеттан тыш дәүләт фондларын төзү тәртибе**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Хөкүмәте бюджеттан тыш дәүләт фондларын гамәлгә куючылар була алалар.

Бюджеттан тыш дәүләт фондларының гамәлгә кую документлары бюджеттан тыш тиешле дәүләт фондын төзү турында гамәлгә куючы карарыннан, аның хакындагы гамәлгә куючы раслаган нигезләмәдән (уставтан) гыйбарәт була.

Бюджеттан тыш дәүләт фондларын дәүләт теркәве законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

4 статья. **Бюджеттан тыш дәүләт фондларының мөлкәте һәм барлыкка килү чыганаклары**

Бюджеттан тыш дәүләт фондларының мөлкәте гамәлгә куючы тапшырган мөлкәттән һәм законнар нигезендә башка мөлкәттән барлыкка килә.

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары мөлкәте аларга оператив идарә хокукында тапшырыла һәм дәүләт милке була.

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчалары җыемнар, түләмнәр, акча күчерүләр, штрафлар һәм законнар белән тыелмаган башка чыганаклар исәбенә барлыкка килә.

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчалары, әгәр законнар белән башкасы каралмаса, башка бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчалары исәбенә барлыкка килә алмый.

Бюджеттан тыш дәүләт фондының акчаларын җыюны,

тулы һәм вакытында булдыруны законнар билгеләгән тәртиптә дәүләт органнары тикшереп торалар.

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары закон белән каралган барлык түләмнәрне, җыемнарны, акча күчерүләрне, шулай ук пени суммаларын законнар нигезендә бәхәссез тәртиптә эзләтеп алырга хокуклылар.

5 статья. **Бюджеттан тыш дәүләт фондларына идарә итү органнары**

Бюджеттан тыш дәүләт фондларына идарә итүче иң югары орган - бюджеттан тыш дәүләт фонды Советы (Идарәсе), ул тикшереп тору һәм күрсәтмә бирү функцияләрен башкара.

Бюджеттан тыш дәүләт фондларының башкарма органы фондның агымдагы эшчәнлеген башкара һәм бюджеттан тыш дәүләт фонды Советы (Идарәсе) алдында хисап тота.

Советның (Идарәнең) барлыкка килү тәртибе, эшчәнлеге һәм вәкаләтләре Бюджеттан тыш дәүләт фонды турындагы нигезләмә (устав) белән билгеләнә.

6 статья. **Бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчаларын булдыру һәм аларны тоту**

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчаларын барлыкка китерү чыганаклары әлеге фондны гамәлгә куючы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә.

Бюджеттан тыш дәүләт фондларына җыемнарның, түләмнәрнең һәм башка мәҗбүри акча күчерүләрнең төрләре, ставка күләмнәре законнар белән билгеләнә.

Бюджеттан тыш дәүләт фонды акчаларыннан файдалану тәртибе фонд турындагы нигезләмә (устав) нигезендә билгеләнә.

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчалары катгый рәвештә фондның максатларына һәм бурычларына туры китереп файдаланыла.

7 статья. **Максатчан бюджет фондлары**

Татарстан Республикасының бюджет системасы турында Татарстан Республикасы Законы нигезендә бюджеттан тыш дәүләт фондлары акчалары Татарстан Республикасының республика бюджетында (максатчан бюджет фондларында) берләштерелергә мөмкин.

Максатчан бюджет фондлары бюджеты Татарстан Республикасы законы белән раслана.

Максатчан бюджет фондлары акчалары белән идарә итүне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы гамәлгә ашыра.

8 статья. **Бюджеттан тыш дәүләт фондлары эшчәнлеген тикшереп тору**

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары эшчәнлеген тикшереп тору законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

9 статья. **Бюджеттан тыш дәүләт фондлары эшчәнлеген туктату**

Бюджеттан тыш дәүләт фондлары үз эшчәнлекләрен законнар нигезендә туктаталар.

10 статья. **Әлеге Законны гамәлгә кертү турында**

Әлеге Законны матбугатта басылган көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 26 мае
№ 2183

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 568. Татарстан Республикасында уен бизнесына салым ставкалары турында

1 статья. Бу Закон Татарстан Республикасы терри-ториясендәге уен йортлары өчен "Уен бизнесына салым турында" Федераль закон нигезендә бердәм салым ставкаларын билгели.

2 статья. Уен бизнесына салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

уен йорты як буларак катнаша торган комарлы уеннар уткәрү өчен билгеләнгән һәр уен өстәле өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 2400 минималь күләмендә;

уен йорты оештыручы һәм (яки) күзәтүче буларак катнаша торган комарлы уеннар уткәрү өчен билгеләнгән һәр уен өстәле өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 200 минималь күләмендә;

һәр уен автоматы өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия

Федерациясе законнары билгеләгән 90 минималь күләмендә;

һәр тотализатор кассасы өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 2400 минималь күләмендә;

букмекер конторасының һәр кассасы өчен - елына хезмәткә түләүнең Россия Федерациясе законнары билгеләгән 1200 минималь күләмендә.

3 статья. Уен бизнесына салым суммасының "Уен бизнесына салым турында"гы Федераль закон билгеләгән салым ставкасының минималь күләменнән арткан өлеше Татарстан Республикасы бюджетына күчерелә һәм 1999 елда, 50 шәр процент итеп, Татарстан Республикасының республика бюджетына һәм җирле бюджетларга бүлеп бирелә. Алдагы елларда салымны Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар арасында бүлүне чираттагы финанс елына Татарстан Республикасының бюджет системасы турындагы Татарстан Республикасы законы билгели торган нормативлар буенча башкарырга.

4 статья. Әлеге Законны матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты үзенең норматив-хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 27 мае
№ 2192

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 569. "1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

1 статья. "1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында" Татарстан Республикасы Законына

(Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, №12) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 3 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1998 елда гамәлдә булган җир өчен салым ставкасы, авыл хуҗалыгы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шулай ук гражданнарга шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек, печән чабу һәм терлек көтү өчен бирелгән авыл хуҗалыгы җирләреннән гайре, барлык категория җирләр өчен 1999 елда 2 коэффициенты белән кулланыла, дип билгеләргә. Су хуҗалыгы системаларыннан алына торган су өчен түләүне исәпләгәндә, 1999 елда 1998 елга билгеләнгән ставкаларны сакларга".

7 статьяда:

"а" пунктчасында "22 процент күләмендә" дигән сүзләрне "19 процент күләмендә" дигән сүзләргә алыштырырга,

"б" пунктчасында "30 процент күләмендә" дигән сүзләрне "27 процент күләмендә" дигән сүзләргә алыштырырга;

түбәндәге редакциядә икенче һәм өченче өлешләр өстәргә:

"Промышленность предприятиеләре һәм башка товар җитештерүчеләр 1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын төзегәндә исәпкә алынган фараз күрсәткечләреннән артык җитештерелгән һәм сатылган продукция (эш башкару, хезмәт күрсәтү) күләменә табышка салымның Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче өлешен 1999 елда түләүдән азат ителәләр, дип билгеләргә.

Югарыда күрсәтелгән предприятиеләргә һәм оешмаларга өстенлекле ташламалар бирү шарты аларның агымдагы түләүләрне үз вакытында һәм тулысынча түләүне тәэмин итүләреннән гыйбарәт. Алынмый калган керемнәр шул ук кварталда компенсацияләнгәндә агымдагы түләүләрне кертү вакытын кварталга иң күбе ике мәртәбә үтәмәгәндә дә, өстенлекле ташламалар алу хокукы сакланырга мөмкин.

Дәүләт хакимиятенең җирле органнарына табышка салымның җирле бюджетларга кертелә торган өлешендә шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә".

3. 12 статьяны түбәндәге редакциядәге дүртенче, бишенче, алтынчы өлешләр белән тулыландырырга:

“Промышленность предприятиеләре һәм башка товар җитештерүчеләр Татарстан Республикасының республика бюджетын төзегәндә исәпкә алынган фараз күрсәткечләреннән артык җитештерелгән һәм сатылган продукция (эш башкару, хезмәт күрсәтү) күләменә өстәлгән бәягә салымның Татарстан Республикасының республика бюджетына кертелүче өлешен, автомобиль юлларыннан файдаланучылардан алына торган салымны, Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фондына кертемнәрне түләүдән азат ителәләр, дип билгеләргә.

Югарыда күрсәтелгән предприятиеләргә һәм оешмаларга өстенлекле ташламалар бирү шарты аларның агымдагы түләүләрне үз вакытында һәм тулысынча түләүне тәэмин итүләреннән гыйбарәт. Алынмый калган керемнәр шул ук кварталда компенсацияләнгәндә, агымдагы түләүләрне кертү вакытын кварталга иң күбе ике мәртәбә үтәмәгәндә дә, өстенлекле ташламалар алу хокукы сакланырга мөмкин.

Өстенлекле ташламалар бирүгә бәйле рәвештә янга калган акчалар билгеләнгән тәртиптә расланган бизнес-планнарда каралган чараларны предприятиеләр һәм оешмалар тарафыннан финанслауга җибәрелә”.

15 статьяда:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“- предприятиеләр һәм оешмалар табышына (керемена) салым 599159”;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“- акцизлар 1412000”.

5. 17 статьяның икенче абзацында “ норматив буенча ставка 35 процент булганда — 13 процент” дигән сүзләрне “норматив буенча ставка 30 процент булганда — 11 процент” дигән сүзләргә алыштырырга.

6. Түбәндәге эчтәлекле $41^1$ статья өстәргә:

“$41^1$ статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты промышленность предприятиеләре һәм оешмаларының Татарстан Республикасының республика бюджетына салымнар, җыемнар һәм исәпләнгән пенялар, шулай ук салым турындагы законнарны бозган өчен штрафлар буенча 1999 елның 1 апреленә җыелган бурычларын салымнар һәм җыемнар буенча бер елга җыелган бурычларны өч ел

дәвамында каплау нигезендә кичектереп тору юлы белән реструктуризацияләргә тиеш.

Югарыда күрсәтелгән предприятиеләр һәм оешмаларга бурычларын каплау вакытын кичектереп тору шарты аларның кичектерелгән барлык вакыт эчендә агымдагы түләүләрне үз вакытында һәм тулысынча түләүне тәэмин итүләреннән гыйбарәт. Алынмый калган керем шул ук кварталда компенсацияләнгәндә, агымдагы түләүләрне кертү вакытын кварталга иң күбе ике мәртәбә үтәмәгәндә дә, реструктуризацияләү хокукы сакланырга мөмкин.

Кичектерү бирү шартларын үтәгәндә, 1999 елның 1 апреленә булган хәлендә пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммасының дүрттән бер өлеше, бер үк вакытта пенялар һәм штрафлар буенча калган бурычларны түләүне алдагы елга кичектереп, кичектерүнең соңгы елында тулысынча бетергәнгә кадәр, ел саен юкка чыгарыла.

Реструктуризацияләгәндә түләү вакыты кичектерелгән һәм озайтылган түләүләр суммасы өчен елына 5 процент күләмендә түләү алына".

2 статья. Әлеге Законны матбугатта басылган көненнән гамәлгә кертергә.

**Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев**

Казан шәһәре,
1999 елның 27 мае
№ 2193

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 570. 1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотик чараларны явыз ниятләрдә куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы гамәлләрнең республика комплекслы программасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан тәкъдим ителгән 1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотик чараларны явыз ниятләрдә куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы гамәл-

ләрнең республика комплекслы программасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон прпоектлары эшләүне планлаштыруны оештырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы наркоманиягә каршы көрәшне көчәйтүне һәм хокук саклау органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итә торган закон проектларын өстенлекле дип санарга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты 2000-2001 елларга Татарстан Республикасының республика бюджетын төзегәндә 1999-2001 елларга Татарстан Республикасында наркотик чараларны явыз ниятләрдә куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы гамәлләрнең республика комплекслы программасын үтәү өчен өлешчә акча бүлеп бирүне күздә тотарга һәм, кирәк булса , Татарстан Республикасы Дәүләт Советына әлеге программага үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 26 мае
№ 2175

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 571. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 16 июньдәге утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 16 июньдәге утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. "Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

2. "Хәйрия эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

3."Җир асты байлыклары турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында"

Татарстан Республикасы законы проекты турында.

4. “Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

5.“Экология экспертизасы турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. Татарстан Республикасының Су кодексы проекты турында.

7. “Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. “16 яше тулмаган балигъ булмаганнарның терроризм акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

9. “Җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

10.“Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

11. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының 9 гыйнвар исемендәге поселогын Тенеш поселогы дип үзгәртеп исемләү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

12. “Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында” Татарстан Республикасы Законын 1999 елның I кварталында үтәүнең барышы хакында.

13. “Татарстан Республикасында көн күрерлек минимум турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күрә торган чаралар хакында.

14. “Татарстан Республикасы мировой судьяларының гомуми саны һәм суд участоклары саны турында” федераль законы проектын Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2206

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 572. Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау һәм Татарстан Республикасы Чирмешән район суды рәисен, Татарстан Республикасының Әлмәт, Түбән Кама шәһәр судлары рәисләренең урынбасарларын раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 89 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Судьялар итеп сайларга:

Татарстан Республикасының Әлмәт шәһәр судына

Җамалетдинов Фәрит Фәметдин улын һәм аны әлеге суд рәисе урынбасары итеп расларга,

Талипова Зөлфия Сәлимулла кызын;

Казан шәһәренең Вахитов район судына

Селиваненко Валентина Александровнаны;

Татарстан Республикасының Зеленодол шәһәр судына

Кириллова Татьяна Николаевнаны;

Казан шәһәренең Киров район судына

Кочемасов Алексей Николаевичны;

Татарстан Республикасының Лениногорск шәһәр судына

Әхмәтшина Роза Госман кызын;

Татарстан Республикасының Түбән Кама шәһәр судына

Гыймранов Рөстәм Габдулла улын һәм аны әлеге суд рәисе урынбасары итеп расларга;

Татарстан Республикасының Тукай район судына

Камалова Саҗидә Исхак кызын;

Татарстан Республикасының Чирмешән район судына

Токтаров Виталий Ивановичны һәм аны әлеге суд рәисе итеп расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2207

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 573. Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының 9 гыйнвар исемендәге поселогын Тенеш поселогы дип үзгәртеп исемләү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының 9 гыйнвар исемендәге поселогын Тенеш поселогы дип үзгәртеп исемләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне№
2207

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 574. "Татарстан Республикасы мировой судьяларының гомуми саны һәм суд участоклары саны турында" федераль закон проектын Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы һәм "Россия Федерациясендә мировой судьялар турында" Федераль законның 4 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына "Татарстан Республикасы мировой судьяларының гомуми саны һәм суд участокларының саны турында" федераль закон проектын һәм аңа кушымталарны кертергә.

2. "Татарстан Республикасы мировой судьяларының гомуми саны һәм суд участокларының саны турында" федераль закон проектын килештерү өчен Россия Федерациясе Югары Судына җибәрергә.

3. “Татарстан Республикасы мировой судьяларының гомуми саны һәм суд участокларының саны турында” федераль закон проектын Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. “Татарстан Республикасы мировой судьяларының гомуми саны һәм суд участокларының саны турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кертелгән федераль закон проектын карауда катнашу өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе рәисе Рәшит Гаяз улы Вәгыйзовны Россия Федерациясенең Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле итеп җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2209

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 575. “Җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. “Җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән искәрмәләрне, тәкъдимнәрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Әлеге закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 16 июленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясенә кертелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы, җирле үзидарә һәм тышкы багланыш мәсьәләләре комиссиясе, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә

алып, 1999 елның 16 августына кадәр әлеге закон проектын эшләп бетерергә һәм икенче укылышка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2210

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 576. "Наркотик чараларга һәм психотроп матдәләргә бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Наркотик чараларга һәм психотроп матдәләргә бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә 1999 елның 16 июленә кадәр җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе 1999 елның 16 августына кадәр, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм икенче укылышка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2211

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 577. “16 яше тулмаган балигъ булмаганнарның терроризм акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында” Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. “16 яше тулмаган балигъ булмаганнарның терроризм акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында” Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 1999 елның 16 июленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясенә җибәрелә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Закон чыгару, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре комиссиясе 1999 елның 16 августына кадәр, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алып, күрсәтелгән закон проектын эшләп бетерергә һәм икенче укылышта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2212

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 578. "Татарстан Республикасында көн күрерлек минимум турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күрә торган чаралар хакында

"Татарстан Республикасында көн күрерлек минимум турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күрә торган чаралар хакында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Г.И.Конюшева мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасында көн күрерлек минимум турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күрә торган чаралар хакында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Г.И.Конюшева мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты "Татарстан Республикасында көн күрерлек минимум турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча өстәмә чаралар күрергә һәм 1 июльгә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хәбәр итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2213

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**579. "Хезмәт ветераны" исеме бирүгә гаризаларны һәм документларны кабул итү, аларны исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм аны тапшыру тәртибе турындагы инструкцияне раслау хакында" Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге 1030 нчы карарының Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм гамәлдәге законнарга туры килүе турында" Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитетының 1999 елның 16 февралендәге бәяләмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күргән чаралар хакында мәгълүмат турында**

Татарстан Республикасы халык депутаты Прохоров Ю.П. таләбе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы

**карар бирә:**

"Хезмәт ветераны" исеме бирүгә гаризаларны һәм документларны кабул итү, аларны исәпкә алу һәм карау, хезмәт ветераны таныклыгын тутыру һәм аны тапшыругы тәртибе турында инструкцияне раслау хакында" Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 1996 елның 9 декабрендәге 1030 нчы карарының Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм гамәлдәге законнарга туры килүе турында" Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитетының 1999 елның 16 февралендәге бәяләмәсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты күргән чаралар хакында мәгълүматны игътибарга алырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2214

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 580. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының язгы сессиясен озайту турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының язгы сессиясен 1999 елның 20 июленә кадәр озайтырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 16 июне
№ 2215

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 581. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елгы язгы сессиясенең чираттагы утырышын 1999 елның 16 июнендә чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 7 июне
№ 2195

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 582. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 16 июньдәге утырышы көн тәртибенә кертелүче мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 16 июньдә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. "Хәйрия эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

2. “Җир асты байлыклары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

3. “Атмосфера һавасын саклау һәм аннан нәтиҗәле файдалану турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

4. Татарстан Республикасының Су кодексы проекты турында.

5.“Экология экспертизасы турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. “Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. “16 яше тулмаган балигъ булмаганнарның терроризм акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

8. “Җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында” Татарстан Республикасы законы проекты турында.

9. “Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында” Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

10. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы районының 9 гыйнвар исемендәге поселогын Тенеш поселогы дип үзгәртеп исемләү турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

11. “Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында” Татарстан Республикасы Законын 1999 елның I кварталында үтәүнең барышы хакында.

12. “Татарстан Республикасының аерым район, шәһәр судлары судьяларын сайлау турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 7 июне
№ 2196

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 583. 1999 елның 26 июнендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертелүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1999 елның 16 июнендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карарлары проектларын кертергә:

1. "Хәйрия эшчәнлеге турында" Татарстан Республикасы законын кабат карау хакында.

2. "16 яше тулмаган балигъ булмаганнарның терроризм акты турында күрәләтә ялган хәбәр иткәннәре өчен ата-аналарның яисә аларны алыштыручы затларның административ җаваплылыгы хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

3. "Җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

4. "Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән бәйле хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

5. "Татарстан Республикасы гражданнарын медицина иминләштерүе турында" Татарстан Республикасы Законын 1999 елның I кварталында үтәүнең барышы хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәмmәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 7 июне
№ 2197

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 584. Татарстан Республикасы халык депутатларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы утырышында әйтелгән тәкъдимнәре турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы халык депутатларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 20 маендагы утырышында Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты адресына әйтелгән тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрергә (кушымтада).

2. Карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 7 июне
№ 2204

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 585. Татарстан Республикасы халык депутатларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 26-27 маендагы XIX пленар сессиясендә әйтелгән тәкъдимнәре турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы халык депутатларының

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 26-27 маендагы XIX пленар сессиясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы адресына әйтелгән тәкъдимнәрен үтәү чаралары планын расларга (1 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы халык депутатларының Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1999 елның 26-27 маендагы XIX пленар сессиясендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты адресына әйтелгән тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты каравына җибәрергә (2 нче кушымта).

3. Карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы халык депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре В.Н.Липужинага йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 7 июне
№ 2205

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 586. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен 1999 елның 2 июлендә дәвам итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 июне
№ 2222

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 587. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына түбәндәге өстәмә мәсьәләләрне кертергә:

1. 21 нче Аксубай административ-территория сайлау округы буенча Татарстан Республикасы халык депутатын сайлаулар нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматы.

2. "Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

3. Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

4. "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проекты турында.

5. "Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

6. "Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

7. "Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил турында" Татарстан Республикасы законы проекты хакында.

8. "Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында" Татарстан Республикасы Югары Советы карарына үзгәреш кертү хакында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты турында.

9. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламен-

тына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

10. Татарстан Республикасының кайбер халык депутатларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

11. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы составында үзгәреш турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

12. "Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль мәсьәләләр һәм яшьләр эшләре даими комиссиясе составында үзгәрешләр турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты хакында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 июне
№ 2223

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 588. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына кертелүче өстәмә мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарлары проектлары турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе каравына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының түбәндәге карар проектларын кертергә:

1. "Татарстан Республикасының сайлау системасын камилләштерү белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

2. "Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

3. "Татарстан Республикасы халык депутатларының җирле Советлары халык депутатларын сайлаулар турында"

Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү турында.

4. "Татарстан Республикасының Үзәк сайлау комиссиясе турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

5. Татарстан Республикасы Конституциясенең 89, 94 статьяларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

6. "Татарстан Республикасының кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкиле турында" Татарстан Республикасы законы проектын эшләүне дәвам итү хакында.

7. Татарстан Республикасының аерым халык депутатлары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 18 июне
№ 2224

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 589. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен дәвам итү көнен үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен дәвам итү турында" Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 1999 елның 18 июнендәге карарын үзгәртеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унтугызынчы пленар сессиясе эшен дәвам итүне Казан шәһәрендә 1999 елның 2 июленнән 5 июленә күчерергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
1999 елның 28 июле
№ 2233

## Искәрмәләр өчен